## КИЛ, ИРКӘМ, КИЛ ИНДЕ

*БӘХТИ ГАЙСИН көе*
*РАГИДӘ ЯНБУЛАТОВА сүзләре*

Ак чәчәк ата балан
Күмелгәч гөлгә ялан.
Яшь йөрәк еш тибә,
Искән җилләр миңа
“Сөйгәнең килә”, = дисә.

*Кушымта:*
Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, кил инде
Кил, иркәм, кил инде
Елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине.

Алып кил миңа язның
Чәчәкле асыл таңын,
Мәхәббәтнең сафын,
Энҗеләргә хасын,
Алып кил миңа тагын

*Кушымта:*
Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, кил инде
Кил, иркәм, кил инде
Елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине.